

Туган илебез гаять кvпторле, анын коче дә нәкъ менә шунда: гасырлар дәвамында гажәеп зур кинлекләрдә торле милләт һәм дин вәкилләре дус-тату гомер итә. Кvпмилләтле Мордовиябездә ел саен рус, татар, мордва һәм башка телләргә багышланган бәйрәмнәр vткәрәбез. Ә бvген рус теле турында татарча язабыз.      Әле генә Псковта оченче тапкыр vз гомерләрен боек рус телен сак- лауга һәм арттыруга багышлаган кешеләрне жәлеп итv vзәгендә (2026 елнын 4 июненнән 7 июньгә кадәр) Ботенроссия рус теле һәм әдәбияты укытучылары форумына 200дән артык педагоглар жыелды. Бу Россия-нен 64 регионыннан һәм Абхазиядән фикердәшләрне, новаторларны һәм традицияләрне саклаучыларны бер-ләштергән чын вакыйга. Россия халыклары бердәмлеге елында әлеге форум халыкларны берләштерvче коч.

Мордовия Республикасы вәкилләре арасында Рузаевка районынын «Тат.-Пишленская СОШ» мәктәбенен рус теле һәм әдәбияты укытучысы Светлана Федоровна Медведева да бар иде. Форум идеяләр алмашу, актуаль проблемалар турында фикер алышу, рус теле һәм әдәбиятын укытуда новаторлык чишелешләр эзләv очен уникаль момкинлек бирде.

Форум кысаларында мастер-класс лар, тvгәрәк остәлләр, пленар утырышлар узды; анда әйдәп баручы белгечләр һәм практик укытучылар vз методикаларын тәкъдим иттеләр, унышлы кейслар белән ур-таклаштылар һәм заманча белем бирv алдында торган мәсьәләләр турында фикер алыштылар. Уку процессында яна технологияләрне куллану, vсеп килvче буында укучылар грамоталылыгын vстерv һәм укучыларда рус әдәбиятынын байлыгын тирәнтен анлау формалаштыру мәсьәләләренә аерым игътибар бирелде.



Светлана Федоровна Медведева һәм башка катнашучылар очен бу форум һонәри vсеш мәйданчыгына гына тvгел, ә илһам чыганагына да әверелде. Барлык катнашучылар «Пушкин диктанты: Псков янгырашы» нда катнаштылар, шәһәрнен тарихи урыннары буенча «Монда Россия башлана» экскурсияләре оештырылды, Печора шәһәрендә, Псково-Печерский монастыренда булдылар, монастырьнын жир асты урамнары буйлап йорделәр. Алтынчы июньдә, А.С.Пушкиннын туган конендә, Святогорск монастыре территориясендәге шагыйрь каберен, «Михайловский» музей-тыюлыгын карадылар, тематик мәйданчыклар Бугрово авы-лынын тарихи урынында оештырылган иде.
Әйтеп китәргә кирәк, әлеге чарада Светлана Федоровна Медведева Ботенроссия эс-се конкурсы лауреаты дипломы белән бvләкләнә. Анын очен бу кон vзенчәлекле, тирән мәгънәгә ия булды. Ул:
- Хезмәттәшләр белән аралашу, фикер алышу, ижат атмосферасына чуму һәм камиллеккә омтылу булды. Псков жире, vзенен матур пейзажлары һәм кvп гасырлык тарихы белән рус теленен матурлыгы турында vзе сvзләр пышылдаган кебек укытучыларны яна казанышларга рухландыра.
Педагоглар кыйммәтле бе лемнәрен генә тvгел, бәлки киләчәк буыннар очен рус мәдәниятенен бәһасез мирасын бергәләп сакларга һәм арттырырга бурычлы булуларына ышанычларын да vзләре белән алып, таралышып йорделәр.
Бу минутларда А.С.Пушкиннын боеклеге тарих факты буларак кына тvгел, ә ил-һамландыручы һәм юнәлеш бирvче тере булуы буларак тоелды. Анын сvзләре, образлары, фикерләре буыннар йорәгендә, рус телендә әйтелгән һәр сvздә яшәвен дәвам итә.
Светлана Федоравна рус әдә-биятын укытучы, саклаучы һәм киләчәк буынга тапшыручы буларак, бу конне vзенен миссиясен аеруча нык тоя.

**Наилә НАСЫРОВА**